| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***<br>***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***<br>***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |
|---|---|

# КАРАР

# РЕШЕНИЕ

1июнь 2026 ел №2-14

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советының »Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 29 мартындагы № 1-41 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы (ред.28`.12`.2025), 2025 елның 20 мартындагы 33 ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнар, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының нигезендә һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәр Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советының »Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 29 мартындагы № 1-41 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Буа шәһәр Советының 29.03.2019 елгы 1-41 номерлы карарына кушымтаның 15.1 пунктының 5 пунктчасында, 2.5 пунктында һәм 9.2 пунктында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Буа шәһәр Советының 29.03.2019 елгы 1-41 номерлы карарына кушымтаның 9.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органы бетерелгәндә, аның шәхси эше саклауга ябылган җирле үзидарә органы функцияләре тапшырыла торган җирле үзидарә органына яисә аның хокукый варисына тапшырыла..»;

1.3. Буа шәһәр Советының 29.03.2019 елгы 1-41 номерлы карарына кушымтаның 22.2 өлешендәге «в» пунктчасында һәм 18.8 пунктында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.4. Буа шәһәр Советының 29.03.2019 елгы 1-41 номерлы карарына кушымтаның 20.2 пунктын «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен һәм «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.5. Буа шәһәр Советының 29.03.2019 елгы 1-41 номерлы карарына кушымтаның 5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт вазыйфасы - муниципаль берәмлек уставы нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органындагы вазыйфа, җирле үзидарә органының яисә муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән бурычлар даирәсе булган вазыйфа.»;

1.6. Буа шәһәр Советының 29.03.2019 елгы № 1-41 карарына кушымтаның 7.4 пунктындагы 5 пунктчасында «һәм квалификация турында» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм районның рәсми сайтында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Камартдинов